ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
04.04.2018

КАРАР
№ 30

с. Введенская Слобода

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге торак пунктларын төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгы үткәрү турында

Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең торак пунктларын төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм халыкның экологик иминлегенә җавап бирә торган хәлгә китерү өчен

КАРАР БИРӘМ:

1. 2018 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Введенский Бистәсе авыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгын игълан итәргә (алга таба - ике айлык).
2. Введенский Бистәсе авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составын 2018 елга расларга. (1-нче кушымта).
3. 2018 елның 01 апреленнән 31 маена кадәрге чорда Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү чаралары планын расларга. (2-нче кушымта).
4. Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждениеләр җитәкчеләренә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, үзләренең якын территорияләрен санитар чистарту эшен оештырырга, каты көнкүреш калдыкларын полигонга һәм чүплекләргә чыгару өчен йөк автотранспорты бүлеп бирергә тәкъдим итәргә. Урыннарда агач һәм куаклар утырту, биналарның фасадларын, балалар мәйданчыкларын ремонтлау эшләрен оештырырга.
5. Авыл җирлеге территориясендә күчемсез милеккә ия булган гражданнарга үз йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш үткәрүне тәкъдим итәргә.
6. Әлеге карарны Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге   башлыгы   Д.В.Морозов

Югары Ослан муниципаль
районы Введенский Бистәсе
авыл җирлеге Башкарма
комитетының
№ 30 апрель 04.04.2018 ел
карарына
1 нче кушымта

Введенский Бистәсе авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составы

1. Морозов Дмитрий Владимирович - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы

2. Петров Владимир Павлович - 6 нчы Петропавлов бермандатлы сайлау округы буенча депутат

3. Алсуфьева Елена Юрьевна - Введенский Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре

4. Вәгыйзова Сәвия Вәгыйз кызы - 5 нче Савиново бермандатлы сайлау округы буенча депутат

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов

Югары Ослан муниципаль
районы Введенский Бистәсе
авыл җирлеге Башкарма
комитетының
№ 30 апрель 04.04.2018 ел
карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә ике айлык кысаларында санитар-экологик хәлне яхшыртуга юнәлтелгән төзекләндерү һәм санитар чистарту чаралары планы

| № | Чараның атамасы | Үткәрү датасы | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан чүп-чар өемнәрен барлау һәм бетерү эшләрен башкару | Апрель ае | Введенский Бистәсе авыл җирлеге депутатлар корпусы |
| 2. | Торак пунктлар территориясендә чүп-чар җыю | Апрель ае | Введенский Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты депутат корпусы |
| 3. | Шәхси торак йортларның йорт яны территориясен җыештыру | Апрель ае | Введенский Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты халык |
| 4. | Авыл җирлеге территориясендә торак пунктлар эчендәге баганаларны агарту | Май ае | Введенский Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты Введенский Бистәсе төп гомуми белем бирү мәктәбе, «Введенсий Бистәсе балалар бакчасы» МББМУ |
| 5. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждениеләрнең, предприятиеләрнең фасадларын ремонтлау | Май айлары | Учреждениеләр, предприятиеләр җитәкчеләре |
| 6. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү (коймаларны ремонтлау, коймаларны буяу, чүп-чарны чыгару) | Май ае | Введенский Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты халык |
| 7. | Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты | Май ае | Введенский Бистәсе авыл җирлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бинасы территориясен төзекләндерү | | башкарма комитеты |
| 8. | Введенский  Бистәсе торак пунктларында яшел үсентеләр утырту | Май ае | Введенский Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты Введенский Бистәсе төп гомуми белем бирү мәктәбе, |
| 10. | Сәүдә мәйданчыкларында һәм җәмәгать туклануы объектларында санитар-гигиеник таләпләрне үтәү һәм төзекләндерү буенча эшләр башкару | Даими | Сәүдә нокталары һәм җәмәгать туклануы пунктлары хуҗалары |

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге   башлыгы          Д.В. Морозов